ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**15.07.2019**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1448**

2017-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районының «Мәдәниятне үстерү нокталары» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Мәдәният өлкәсен тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру максатыннан, Зеленодолск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 17 гыйнварындагы 53нче номерлы карары белән расланган 2017-2020 елларга Зеленодольск муниципаль районының «Мәдәният үсеше нокталары» мәдәният үсеше муниципаль программасына әлеге карарга кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. ЯҮМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге җитәкчесенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет " мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.В.Лулаковка йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сапожников

Кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
15.07.2019 №1448

**Программаның паспортында «Күләме һәм финанслау чыганаклары» пунктының 2 нче графасын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:** «Әлеге программаны гамәлгә ашыруга бәйле чараларны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә тиешле финанс елына гамәлгә ашырыла. Программаны тормышка ашыруга тотылган акчаларның күләме район бюджеты, Зеленодольск муниципаль районы территориясендә инфляция процесслары һәм икътисадый вәзгыять мөмкинлекләреннән чыгып төгәлләштерелергә һәм төзәтмәләр кертелергә мөмкин».